Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлеге составына керүче Яңа Тинчәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре

22 декабрь 2021 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Яңа Тинчәле авыл җирлегенең Яңа Тинчәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Яңа Тинчәле авылында юлларны кышкы чорда карап тоту, җәйге чорда территорияне карап тотуга (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә), контейнер мәйданчыкларын төзекләндерүгә, хуҗасыз йорт хуҗалыкларын коймалар белән тәэмин итү өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2021 елның декабрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә, халык җыенында катнашучылар исемлегенә 448 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны- 331 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 306 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 5 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлеге составына керүче Яңа Тинчәле авылында халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Яңа Тинчәле авыл җирлегенең Яңа Тинчәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Яңа Тинчәле авылында юлларны кышкы чорда карап тоту, җәйге чорда территорияне карап тотуга (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә), контейнер мәйданчыкларын төзекләндерүгә, хуҗасыз йорт хуҗалыкларын коймалар белән тәэмин итү өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Яңа Тинчәле авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Тинчәле авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: __________ Р.К. Мадышев

Яңа Тинчәле авыл җирлеге
башлыгы __________ Р.К. Мадышев